**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 октябрендәге 4192 номерлы карары**

**Совет районының Фиалковая урамындагы**
**территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе өчен 2023-2024 елларга муниципаль бирем нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2022 елның 8 мартындагы 46-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законның 18 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Совет районының Фиалковая урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) тыш, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) тыш, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә:

5.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую һәм ясала торган җир кишәрлекләренә карата муниципаль милек хокукын теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

5.2. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә.

6. Җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

6.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

6.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 октябрендәге
4192 номерлы карары белән
расланды

**Совет районының Фиалковая урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Әлеге проект белән, милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт ителгән файдалану төре торак йорт төзү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе үстерү булган, 16:50:350103:801 кадастр номерлы җир кишәрлеген; милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт ителгән файдалану төре торак йорт төзү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе үстерү булган, 16:50:350103:817 кадастр номерлы җир кишәрлеген; милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт ителгән файдалану төре гомуми файдаланудагы территория (яшелләндерү) (16 нчы төр) булган, 16:50:350103:1871 кадастр номерлы җир кишәрлеген; милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт ителгән файдалану төре запас (код 12.3) булган, 16:50:350103:2431 кадастр номерлы җир кишәрлеген; милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт

ителгән файдалану төре запас (код 12.3) булган, 16:50:350103:2435 кадастр номерлы җир кишәрлеген; милек хокукында Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган, рөхсәт ителгән файдалану төре мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү булган, 16:50:350103:2939 кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлеп, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясының 3 пункты нигезендә ясала торган :ЗУ1, :ЗУ3-:ЗУ10, :ЗУ13-:ЗУ15 җир кишәрлекләренә 16:50:350103:2431, 16:50:350103:2435 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен (запас (код 12.3)), :ЗУ2, :ЗУ11, :ЗУ12 җир кишәрлекләренә 16:50:350103:1871 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен (гомуми файдаланудагы территория (яшелләндерү) (16 нчы төр)) билгеләп, 15 җир кишәрлеге ясау күздә тотыла.

Кадастр эшләрен башкарганнан соң, ясала торган :ЗУ1-:ЗУ15 җир кишәрлекләренә рөхсәт ителгән файдалану төрен таблица нигезендә билгеләргә кирәк.

<table>
<tr><th>Җир кишәрлеге номеры</th><th>Кишәрлек мәйданы, кв.м</th><th>Кишәрлектән рөхсәт ителгән файдалану төре</th><th>Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры</th><th>Искәрмә</th></tr>
<tr><td>:ЗУ1</td><td>8109</td><td>Мәдәният-ял эшчәнлеге объектлары</td><td rowspan="9">16:50:350103:801, 16:50:350103:817, 16:50:350103:1871, 16:50:350103:2431, 16:50:350103:2435, 16:50:350103:2939, дәүләт милке чикләнмәгән җирләр</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ2</td><td>38078</td><td>Территорияне төзекләндерү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ3</td><td>4331</td><td>Эчке хокук тәртибен тәэмин итү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ4</td><td>4277</td><td>Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ5</td><td>1004</td><td>Элемтә хезмәте күрсәтү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ6</td><td>1007</td><td>Элемтә хезмәте күрсәтү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ7</td><td>1010</td><td>Элемтә хезмәте күрсәтү</td><td>-</td></tr>
<tr><td>:ЗУ8</td><td>1005</td><td>Кибетләр</td><td rowspan="2">Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрен алу процедурасын узу</td></tr>
<tr><td>:ЗУ9</td><td>1005</td><td>Кибетләр</td></tr>
</table>


| Җир кишәрлеге номеры | Кишәрлек мәйданы, кв.м | Кишәрлектән рөхсәт ителгән файдалану төре | Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Искәрмә |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| :ЗУ10 | 1010 | Кибетләр | | шарты белән кибетләр – рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү мөмкин |
| :ЗУ11 | 2011 | Территорияне төзекләндерү | | - |
| :ЗУ12 | 1363 | Территорияне төзекләндерү | | - |
| :ЗУ13 | 2881 | Эчке хокук тәртибен тәэмин итү | | - |
| :ЗУ14 | 3384 | Запас | | - |
| :ЗУ15 | 3351 | Запас | | - |

Җир кишәрлекләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- ихтыяҗ булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

# II. Территорияне ызанлау сызымы



| Условные обозначения | |
|---|---|
| | Граница проекта межевания |
| | Границы существующих земельных участков |
| | Границы образуемых земельных участков |
| | Красные линии существующие |
| | Граница кадастрового квартала |
| | Обозначение исходного земельного участка |
| 16:50:350103:801<br>16:50:350103:817 | Кадастровые номера исходных земельных участков |
| 16:50:350103:11[illegible] | Кадастровый номер существующего земельного участка |
| 16:50:350103 | Номер кадастрового квартала |
| | Зоны с особыми условиями использования территорий |
| | Граница сервитута |
| •4 | Номера характерных точек границ сервитута |
| •1 | Номера характерных точек границ проекта межевания |
| •н1 | Номера характерных точек границ образуемых земельных участков |
| :ЗУ1 | Обозначение образуемых земельных участков |

____________________________